ПРОЕКТ


**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**
Полковая ул., 9, с. Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422701

**«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
Полковая урамы, 9, Биектау поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422701

Тел.: +7 (84365) 3-28-54, e-mail: pizobiektau@mail.ru


---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**28 Гыйнвар 2019 ел** **№ 5-б**

## Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын раслау турында

Гражданнар һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча структур бүлекчәләрнең эшчәнлеген регламентлаштыруны һәм стандартлаштыруны тәэмин итү максатыннан, 2010 нчы елның 27 нче июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы” Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның, 2 нче ноябрендәге 880 нче номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турындагы” карарына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 нче елның 13 нче июнендәге 676 номерлы “Административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен оптимизацияләү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турындагы” карары нигезендә,

1. Түбәндә китерелгән Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентын расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге боерыкны үтәүне контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис С.М.Мингазов

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Милек һәм җир
мөнәсәбәтләре Палатасының
2019 нчы елның 28 Гыйнвар № 5
Боерыгына

**Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең (алга таба – муниципаль хезмәт) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” МКУсе (алга таба – Палата яки Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы).

1.3.1. Палатаның урнашкан урыны: Биектау авылы, Полковая урамы, 9 нчы йорт.

Палатаның эш графигы:
Дүшәмбе, сишәмбе: 8.00 дән 16.00 га кадәр;
пәнҗешәмбе — 8.00 дән 12.00 гә кадәр;
чәршәмбе, җомга – кабул итү көннәре түгел;
шимбә, якшәмбе – ял көннәре;
төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен: 8(84365) 3-28-54.

Керү шәхесне ачыклаучы документлар буенча.

1.3.2. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты адресы (алга таба – “Интернет” челтәре): (http://vysokaya-gora.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Палата биналарында урнашкан гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмати стендларда урнаштырылучы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пукнтларында (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәте турында мәгълүматны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында: (http://www.vysokaya-gora.tatar.ru.);

3 Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә-шәхсән яки телефон буенча;

язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Палата белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Палатаның биналарында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы, 30.11.1994 51-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.) (алга таба – РФ ГК);

Россия Федерациясе Җир кодексы белән 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 ст.);

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар Җыелмасы, 2003, №40, ст.3822);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары Җыелмасы, 2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының “Җир кишәрлегенең урнашу яки территориянең кадастр планында җир кишәрлеге схемасын әзерләүгә һәм җир кишәрлеге урнашу схемасы форматына таләпләрне яки территориянең кадастр планында җир кишәрлекләрен җир кишәрлекләре урнашу схемасын әзерләгәндә яки электрон документ формасында территориянең кадастр планында, яки кәгазь формада әзерләнә торган җир кишәрлегенең урнашу схемасы формасы яки җир кишәрлегенең территориянең кадастр планында җир кишәрлеге урнашу таләпләрен раслау турындагы” 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы Боерыгы (алга таба – 762 номерлы боерык) (Хокукый мәгълүмат рәсми порталы, http://www.pravo.gov.ru, 18.02.2015);

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 03.08.2004, №155-156);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 19 мартында 168 номерлы карары белән расланган “Шәхси милектә булган Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен яки дәүләт милке чикләнгән җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә җир кишәрлекләре артуына түләү күләмен ачыклау тәртибе” (алга таба – Тәртип) (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимият республика органнарының норматив актлары җыелмасы, 03.04.2015, №25, 0857 ст.);

Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Советының 28.09.2016 № 86 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Советның 2019 елның 6 декабрендәге 341 нче номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы” МКУсе турында Нигезләмә (алга таба – Палата турында Нигезләмә);

Палата рәисенең 2011 елның 17 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең еракта урнашкан эш урыны – муниципаль районның авыл җирлекләрендә гариза бирүчеләрнең документларын кабул итү һәм бирү, консультацияләр бирү тәрәзәсе;

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (27.07.2010 ел, №210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст.2 п.). Гариза стандарт бланкта тутырыла (2 нче кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| **Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме** | **Стандартка таләпләр эчтәлеге** | **Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт** |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт исеме | Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү | РФ ҖК 39.29 ст. |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | Палата турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | Җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карар.<br>Расланган территорияне межалау проекты нигезендә, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә рөхсәт.<br>Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар | РФ ҖК 39.29 ст. 8 п.,<br>Палата турында Нигезләмә |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия | Гариза алынган көннән 10 көн[1] эчендә карар кабул итү.<br>Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проектының имзаланган нөсхәләрен гариза бирүчегә имза кую өчен җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең кадастр паспортлары кергән көннән өч эш көненнән артмаган срокта җибәрү. | РФ ҖК 39.29 ст. 8 п.<br><br>РФ ҖК 39.29 ст. 13 п. |

[1].Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы административ процедураларны тормышка ашыру өчен минималь кирәк булган суммар сроктан чыгып билгеләнгән. Административ процедураларның дәвамлылыгы эш көннәрендә исәпләнә

| | | |
|---|---|---|
| Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты | Кадастр эшләрен үткәрүне яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә алу максатларында үтәү срогы һәм килешү проектын имзалау өчен гариза бирүче билгеләгән срок муниципаль хезмәт күрсәтү чорына керми.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен законнар чыгаручы яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) Гариза ( 1 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченеке булган җир кишәрлегенә хокук бирүче яки хокукны раслаучы документларның күчермәләре, әгәр дә милеккә хокук Күчемсез милек дәүләт реестрында теркәлгән булса;<br>3) Җир кишәрлегенең урнашкан урыны схемасы, әгәр дә чикләрендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү тормышка ашырыла торган территорияне межалау проекты булмаса;<br>4) Гариза бирүченең вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, әгәр дә җир кишәрлеген бирү турында мөрәҗәгать белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать итсә;<br>5) Әгәр дә гариза бирүче чит ил юридик заты булса, чит ил законнары нигезендә юридик затның дәүләт теркәве узуы турында документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче палатага шәхсән үзе мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин: | РФ ҖК 39.29 ст. 3 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми керүнең мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар саклананган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алыналар:<br>1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (җир кишәрлегенә хокуклар турында);<br>2) ЕГРЮЛдан мәгълүматлар.<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүченең хезмәт күрсәтүдән баш тартуына нигез булып тормый. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда хезмәт күрсәтү өчен килештерүе таләп ителгән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителә | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документларны тиешле булмаган зат тарафыннан тапшыру;<br>2) Тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага кушып бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген турыдан-туры аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди хилафлыклар булу;<br>4) Документларны тиешле органга тапшырмау | РФ ҖК 39.29 ст. 7 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез каралмаган.<br>1) Җир кишәрлеген яңадан бүлү турында гариза РФ ҖК 39.28 статьясы 1 пунктында каралмаган очракларда бирелгән;<br>2) Әгәр дә яңадан бүленергә тиешле җир кишәрлекләре күрсәтелгән затларның хокуклары белән йөкләнгән булсалар РФ ҖК 11.2 статьясының 4 пунктында күрсәтелгән затларның рөхсәтләре язма формада тәкъдим ителмәгән;<br>3) шәхси милектә һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милек хокуклары килеп туган җир кишәрлегендә һәм (яки) җир кишәрлекләрендә дәүләт яки муниципаль милектә булган, башка гражданнар яисә юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән объект, корылма урнашкан (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында яисә җир кишәрлегендә РФ ҖК 39.36 статьясы 3 пунктында каралган объект урнашкан булуы һәм аларның булуы аның рөхсәт ителгән кулланылуы нигезендә җир кишәрлеген куллануга тоткарлык итми;<br>4) Территорияне межалау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы тарафыннан шәхси милектә булган, һәм яки әйләнештән алынган яисә әйләнештәге чикләнгән дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү күздә тотыла;<br>5) Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен барлыкка китерү шәхси милектә булган, һәм дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм дәүләт һәм муниципаль | п.9 ст.39.29 ЗК РФ |

| | | |
|---|---|---|
| | ихтыяҗлар өчен резервланган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән барлыкка килә;<br>6) Территорияне межалау проекты яки җир кишәрлегенең урнашу схемасы тарафыннан шәхси милектә булган, һәм дәүләт һәм муниципаль милектә булган аукцион предметы булган җир кишәрлеген яңадан бүлү күз алдында тотыла, аны уздыру турында хәбәр РФ ҖК 39.11 статьясы 19 пункты нигезендә урнаштырылган, яисә әлеге җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аны гамәлдә булу срогы тәмамланмаган;<br>7) Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен барлыкка китерү шәхси милектә булган, һәм дәүләт һәм муниципаль милектә булган җир кишәрлеге һәм (яки) җир кишәрлекләре һәм аларга карата җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза яки җир кишәрлеген бирү турында гариза кабул ителгән яки әлеге алдан килештерүдән яки бирүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән;<br>8) Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милек хокуклары иклеп туа торган җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлекләренең билгеләнгән максималь күләмнәреннән артып китәчәк;<br>9) Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен барлыкка китерү шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен һәм РФ ҖК 11.9 статьясы белән күздә тотылган таләпләрне бозмыйча мөстәкыйль рәвештә җир кишәрлеген барлыкка китерергә мөмкин булган, РФ ҖК 39.28 статьясы 1 пунктының 1 һәм 4 пунктчалары нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү очракларыннан кала, яңадан бүлү юлы белән күздә тотыла; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 10) Шәхси милектә булган җир кишәрлекләренең чикләре “Күчемсез милеккә дәүләт теркәве турында” Федераль законы нигезендә тәгаенләнергә тиешле;<br>11) РФ ЖК 11.10 статьясы 16 пункты белән күздә тотылган, җир кишәрлеге урнашу схемасын раслаудан баш тарту өчен нигезләр бар;<br>12) Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасы, барлыкка китерелә торган җир кишәрлегенә карата таләпләрне бозып эшләнгән яки расланган территорияне планлаштыру проектына, җирдә төзелеш алып бару документларына, аеруча саклана торган табигать территорияләре турында нигезләмәләргә туры килми;<br>13) Җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән күздә тотылган җир кишәрлеге территорияне межалау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан;<br>14) документларына, аеручы саклана торган табигать территорияләре турында нигезләмәләргә туры килми;<br>13) Җир кишәрлегенең урнашу схемасы белән күздә тотылган җир кишәрлеге территорияне межалау проекты расланган территория чикләрендә урнашкан;<br>14) Шәхси милек хокукы килеп туган җир кишәрлеге мәйданы, җир кишәрлеге урнашу схемасы яки территорияне межалау проектында күрсәтелгән әлеге җир кишәрлегенең мәйданыннан ун проценттан артыкка артып китсә. | РФ ЖК 39.29 ст. 14 п. |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләре | | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13 Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында соравын, шул исәптән электрон формада да теркәү вакыты | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Электрон формада кергән ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән әлеге объектларның инвалидлар өчен үтү мөмкинлеген тәэмин итүгә, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгын системасы һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (уңайлы керү-бинага чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, | |

| | | |
|---|---|---|
| турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре , шул исәптән мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең эш урыннарында, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре булып тора:<br>җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан бина;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында Муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт алуда комачаулаучы киртәләрне үтәргә ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты булмау белән характерлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләргә документлар кабул итү һәм бирү чиратлары;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорау биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе алган очракта | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлекнең озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (Алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең ерак урнашкан эш урыннарында консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан mfc.tatar.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/), КФҮ дә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләрне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада бирү каралган булса, гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бирелә (http://uslugi. tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы, КФҮ дә<br>(http:// www.gosuslugi.ru/) | |

**3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре**

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;
2) гариза кабул итү һәм теркәү;
3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү;
4) муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү һәм тапшыру;

3.1.2.Муниципаль хезмәт күрсәтү эшчәнлеге эзлеклелеге блок-схемасы 2 нче номерлы кушымтада китерелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

3.2.1. Гариза бирүче палатага шәхсән телефон буенча һәм (яки) электрон почта аша муниципаль хезмәт тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тәкъдим ителә торган документациянең составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы зат яки КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язмача гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Палатага тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формада гариза Палатага электрон почта яки Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризаларны кабул итүче Палата белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклау;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышанычнамә белән эш йөртелсә);

әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килгән документларның булуын тикшерү;

документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү (документ күчермәләрен тиешенчә эшләү, документларда бозулар, өстәүләр, сызылган сүзләр, алдан кисәтелмәгән төзәтүләр булмау).

Кимчелекләр булмаган очракта, Палата белгече түбәндәге эшләрне башкара:

гаризаны кабул итү һәм журналда теркәү;

документларның исемлеге күчермәсен бирү, анда муниципаль хезмәт күрсәтү

вакытын, бирелгән номерны, документларны кабул итү датасын күрсәтү;

гаризаны Палата җитәкчесенә карауга җибәрү.

Документларны кабул итүгә каршылыклар булган очракта, документларны кабул итүче Палата белгече гариза бирүчене гаризаны теркәүгә каршылыклар булуы турында кисәтә һәм, язма формада кабул итүгә каршы булуның сәбәпләрен аңлатып, документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

гариза һәм документларны кабул итү вакыты - 15 минут;

гаризаны теркәү гариза тапшыру моментыннан бер көн эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Палата җитәкчесенә карауга җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм аңа гаризаны җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гариза теркәлгән вакыттын бер көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Палата белгече электрон формада ведомствоара электрон үзара хезмәттәшлек системасы аша ЕГРП һәм ЕГРЮЛдан мәгълүматлар бирү турындагы соратулар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр белгечләре соратып алына торган документлар (мәгълүмат) тапшыралар яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында хәбәрнамәләр җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәге срокларда тормышка ашырылалар:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән дә артмаган вакытта;

башка тәэмин итүчеләр буенча – әгәр дә ведомствоара сорату әзерләү һәм ведомствоара таләпкә җавап җибәрүнең федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, документ һәм мәгълүмат бирүче оешмага кергән көннән биш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү һәм тапшыру

3.5.1. Палата белгече алынган документлар нигезендә карар кабул итә һзм документ проектын әзерли:

җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар;

межалау проекты белән расланган нигездә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүләр төзүгә рөхсәт;

җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар.

Билгеләнгән тәртиптә әзреләнгән докмент проектын килештерү һәм имзалауны процедураларын тормышка ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җаваплар алынган көндә тормышка ашырылалар.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесенә (аның тарафыннан вәкаләтле затка) килештерүгә һәм имзалауга җибәрелгән документлар.

3.5.2. Палата җитәкчесе документ проектынраслый һәм Палатага теркәлү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар моңа кадәрге процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә тормышка ашырылалар.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлергә җибәрелгән имза куелган документ.

3.5.3. Палата белгече документны терки һәм гариза бирүчене (аның вәкилен) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар моңа кадәрге процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә тормышка ашырылалар.

3.5.4. Палата белгече расланган җир кишәрлеге урнашу схемасын, расланган территорияне межалау проекты нигезендә, җир кишәрлекләрен яңадан бүлүгә ризалык турында килешүне яки килешүне төзүдән баш тарту турында карарны гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар имзалаган документны теркәгән көнне тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) җибәрелгән теркәлгән документ.

3.5.5. Гариза бирүче расланган җир кишәрлеге урнашу схемасын, расланган территорияне межалау проекты нигезендә, җир кишәрлекләрен яңадан бүлүгә ризалык турында килешүне алганна соң, расланган территорияне межалау проекты нигезендә тәэмин итә:

җир кишәрлекләренә дәүләт кадастр хисабы максатыннан, нәтиҗәдә яңадан бүлү барлыкка килә торган кадастр эшләре уздыру, һәм әлеге җир кшәрлекләренең дәүләт теркәве турында гариза белән мөрәҗәгать итә;

җир кишәрлекләренә дәүләт кадастр хисабы максатыннан кадастр эшләре башкару, аларга милек хокукын гариза бирүче ала һәм әлеге җир кшәрлекләренең дәүләт теркәве турында гариза белән мөрәҗәгать итә (*дәүләт күчемсез милек кадастрында дәүләт һәм муниципаль милектә булган һәм аларга карата яңадан бүлү тормышка ашырыла торган җир кишәрлеге чикләренең урнашкан урыны турында мәгълүматлар булмау)*;

вәкаләтле органга яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең кадастр паспортын тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүче органның административ регламенты белән билгеләнгән срокларда тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлегенең яки җир кишәрлекләренең тәкъдим ителгән кадастр паспорты.

3.5.6. Палата белгече кадастр паспортын алганнан соң, килешү проектын әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү һәм имзалау процедурасын тормышка ашыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар кадастр паспорты кергәннән соң бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: имза куюга җибәрелгән килешү проекты.

3.5.7. Палата җитәкчесе килешү проектына имза куя һәм теркәлү өчен Палатага җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн дәвамында тормышка ашырыла

Процедуралар нәтиҗәсе: теркәлүгә җибәрелгән имза куелган документ.

3.5.8. Палата белгече документны терки, гариза бирүчегә хәбәр итә һәм имза куелган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проектының нөсхәләрен имза кую өчен гариза бирүчегә бирә (җибәрә).

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура тормышка ашырыла:

килешү проектын бирү – гариза бирүче килгән көнне 15 минут дәвамында, чират буенча;

килешү проектын почта аша хат белән җибәрү – әлеге Регламентның 3.5.7 пунктчасында күздә тотылган процедура тәмамланган вакыттан бер көн эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: җир кишәрлеген бирү турында бирелгән карар яки баш тарту турында хат.

3.5.9. Гариза бирүче килешү проекты нөсхәләренә имза куя һәм Палатага кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алган көннән соң утыз көннән дә соңга калмыйча тормышка ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палатага җибәрелгән имза куелган документ

3.6. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү.

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтелү турында КФҮкә, КФҮнең еракта урнашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. КФҮ аша гаризаларны кабул итү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ эше регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. КФҮдән муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кергәндә, процедуралар әлеге бердәй административ әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталар төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Палатага тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза ( 2 нче кушымта);

гариза бирүчегә техник хата булган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән документ;

юридик көчкә ия, техник хаталар булуын таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларда күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында сорап язылган гаризаны гариза бирүче тарафыннанм (вәкаләтле вәкил) шәхсән үзе, яки почта аша (шул исәптән электрон почтаны кулланып), дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең Бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәге аша тапшыра ала.

3.7.2. Документларны кабул итү буенча җаваплы белгеч техник хатаны төзәтүне сорап язылган гаризаны кабул итә, бирелгән документлар белән бергә терки һәм Палатага тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура гаризаны теркәгән вакыттан бер көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Палата белгеченә каралуга җибәрелгән гариза.

3.7.3. Палата белгече документларны тикшерә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максаты белән гамәлдәге Регламентның 3.5 пункты белән каралган процедураларны башкара һәм төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) имза куйдырып тапшыра һәм гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен ала яки гариза бирүченең адресына почта аша (электрон почта аша) Палатага техник хата булган документ нөсхәсен тапшырып, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылган яки кызыксыну белдергән заттан хата булу турында гариза кабул иткәннән соң өч көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. 4. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә ала: гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының шикаятьләрен карау, үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләү керә.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын хокукый тикшерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә эш кәгазьләрен алып баруны тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән

тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрнең башкарылуын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында Палата җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлеше эзлеклелегенә агымдагы контроль, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Палата рәисе, шулай ук Палата белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлеге белән күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәтне алучылар муниципаль хезмәт тәкъдим итүдә катнашучы Палата хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына)

судка кадәр шикаять белән Палатага яки Башкарма комитетка, Палата җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) муниципаль берәмлек Советына шикаять белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять ителә.

5.2. Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән муниципаль хезмәтне күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмаулауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле

үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәтне алучы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматларны алырга хокуклы.

5.4. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада җибәрелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы “г” бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук

аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр), шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап, унбиш эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының кире кагуын шикаять иткән очракта, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тарткан яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хәреф-хаталарын төзәтүдә яки әлеге төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган вакытта - аны теркәгән көннән башлап, биш эш көне дәвамында.

5.6. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен гариза бирүченең– физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны турында белешмә яисә гариза бирүче- юридик затның исеме, урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәте күрсәтү органы, муниципаль хезмәте күрсәтү органы вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүче килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.7. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар, яисә аларның күчермәләрен тәкъдим ителә ала (булган очракта).

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү

вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаганда гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару;

2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар кичекмәстән юкка чыгару өчен муниципаль хезмәт күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә муниципаль хезмәт алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрелә.

1 нче кушымта
Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Административ регламентына

______________________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)

______________________________________________
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны, шәхесне раслаучы документ реквизитлары, ИНН)

______________________________________________
(юридик затлар өчен - исеме, урнашкан урыны, оештыру-хокук формасы, ЕГРЮЛ, ОГРН да дәүләт теркәве турында мәгълүматлар)

______________________________________________
__________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

**Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча**
**гариза**

Сездән 16:16:___________:____, кадастр номеры (лары) белән җирләрне һәм (яки) җир кишәрлеге (ләре) һәм 16:16:___________:____, кадастр номеры (лары) белән җирләрне һәм (яки) җир кишәрлеге (ләре) белән 16:16:___________:____, кадастр номеры (лары) һәм 16:16:___________:____, кадастр номеры (лары) белән җирләрне һәм (яки) җир кишәрлеге (ләре) яңадан бүлү турында килешү төзүегезне сорыйм.
Адрес(а) земельного (ных) участка(ов) Җир кишәрлегенең(ләр) адресы(лары): Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы,_______________________________________ _______________урамы ___ йорт.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә (сканкүчермәләр):
1) гариза бирүче (гариза бирүчеләрнең), яисә физик яки юридик затның вәкиленең шәхесен ачыклаучы документларның күчермәләре;
2) физик яки юридик затның вәкиле хокукларын (вәкаләтләрен) раслаучы документларның күчермәләре, әгәр дә гариза белән гариза бирүче (гариза бирүчеләрнең) вәкилләре мөрәҗәгать итсә:
3) гариза бирүченеке булган җир кишәрлегенә, биналарга (крылмаларга) хокук бирүче яки хокукны раслаучы документларның күчермәләре;
4) территориянең кадастр планында, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләгән башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән җир кишәрлеге

яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында карар (чикләрендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү тормышка ашырылган территорияне межалау проекты булмаса);

5) җир кишәрлегенең кадастр паспорты, яисә җир кишәрлегенең кадастр өземтәсе, әгәр дә җир кишәрлеге(ләре) аларны барлыкка китерә торган җир кишәрлеге(ләре) турында мәгълүматлар дәүләт күчемсез милек кадастрына кертелгән очракта;

6) чит ил законнары нигезендә юридик затның дәүләт теркәве узуы турында документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе (чит ил законнары нигезендә юридик затның дәүләт теркәве узуы турында документларның рус теленә расланган тәрҗемәсе (әгәр дә гариза бирүче чит ил юридик заты булса).

*Шәхси мәгълүматларны эшкәртү (муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны җыю, системага салу, туплау, саклау, аныклау (үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), блоклау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) өчен мин тәкъдим ителә торган затның ризалыгын, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, килешүләрен раслыйм.*

*Минем шәхесемә кагылышлы һәм минем затка тәкъдим ителгән, шулай ук миңа түбәнрәк кертелгән мәгълүматлар дөрес дип саныйм. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның сканкүчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматлар бар.*

*Миңа бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашырга ризалык бирәм:* ________________________.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | ( ____________________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.И.) |

2 нче кушымта
Муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Административ регламентына

Татарстан Республикасы
________________ муниципаль
районы Милек һәм җир
мөнәсәбәтләре Палатасы рәисенә
___________________________нән

**Техник хатаны төзәтү турында**
**гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ______________________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:____________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_________________________________________________
______________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:_______;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: ________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мине вәкилләгән затның

ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мине вәкилләгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: _______________________.

| | | |
|---|---|---|
| _______________ | __________________ | ( _________________) |
| (дата) | (имза) | (Ф.И.А.И.) |

Кушымта
(белешмә)

## Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Палата рәисе | **3-28-54** | pizobiektau@mail.ru |
| Палата белгече | **3-28-54** | pizobiektau@mail.ru |

### Биектау муниципаль районы Советы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **2-30-50** | Biektau.Sovet@tatar.ru |